Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Бута авылы башкарма комитеты

КАРАРЫ

6 май 2019 ел № 4

Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Бута авылы башкарма
комитеты карарларының
үз көчен югалтуын тану турында

Муниципаль норматив хокукый актларны гамәлдәге законнарга туры китерү белән бәйле рәвештә, хокукый мониторинг нәтиҗәләре буенча

Бута авылы башкарма комитеты
КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Бута авылы башкарма комитетының "Вәкаләтләрнең бер өлешен Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетына тапшыру турында"гы 2011 елның 16 сентябрендәге 12/1 номерлы 1,2,3 пунктларын үз көчен югалткан дип танырга;
2. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Бута авылы башкарма комитетының 2012 елның 09 сентябрендәге № 6/1 «Бута авылы башкарма комитеты вәкаләтләренең бер өлешен Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетына тапшыру турында килешүгә үзгәрешләр кертү хакында 2011 елның 16 сентябрендәге" 12/1 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карарны Бута авылы, Сельская урамы, 28А нче йорт, территориясендә урнашкан махсус мәгълүмати стендларда халыкка җиткерергә, "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар рәсми порталында" (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет" челтәрендә урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны үз артымда калдырам.

Бута авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе Д.Е. Абрамов